# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Сайлаулар һәм референдумнар турында Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 7 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Сайлау кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш); 2010, № 6) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 18 статьяда:

а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 пункты нигезләмәләре территория комиссияләренең Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә яшәргә рөхсәт кәгазе яисә даими яшәү хокукын раслый торган башка документы булган әгъзаларына кагылмый.

Әлеге статьяның 1 өлешендәге 7, 9 һәм 10 пунктлары нигезләмәләре, әгәр кандидат башка сайлау округы буенча күрсәтелгән йә теркәлгән булса, участок, территория һәм округ комиссияләре әгъзаларына кагылмый.";

б) түбәндәге эчтәлекле $8^1$ өлеш өстәргә:

"$8^1$. Әлеге статьяның 8 өлешендәге 1 пункты нигезләмәләре территория комиссияләренең Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә яшәргә рөхсәт кәгазе яисә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ алган әгъзаларына кагылмый.";

в) 13 өлештә беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе, Рәис урынбасары, секретаре Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын билиләр.";

2) 21 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Сайлау комиссияләренең кандидатлар турында белешмәләр булган карарларын бастырып чыгарганда (халыкка җиткергәндә), кандидат паспортының яисә граждан паспортын алыштыра торган документының сериясе һәм номеры, аның бирелү датасы, паспортны яисә граждан паспортын алыштыра торган документны биргән органның исеме яисә коды бастырып чыгарылырга тиеш түгел, ә кандидатның яшәү урыны адресы урынына аның яшәү урыны булган Россия Федерациясе субъектының, районның, шәһәрнең яисә башка торак пунктның исеме күрсәтелә.";

3) 32 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Сайлау берләшмәсенең исеме иҗтимагый берләшмәләрне теркәү өлкәсендәге функцияләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан бирелгән юридик затларның бердәй дәүләт реестрына сайлау берләшмәсе турында язма кертелү фактын раслый торган документта күрсәтелгән исем була. Юридик зат булмаган сайлау берләшмәсенең исеме аны төзү турындагы карарда күрсәтелгән исем була.";

4) 33 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкилләре сайлау берләшмәсе съездының (конференциясенең, җыелышының) карары йә сайлау берләшмәсе уставы нигезендә вәкаләт бирелгән органның карары белән билгеләнеп куелалар. Карарда һәр вәкаләтле вәкилнең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, туган көне, паспортының яисә граждан паспортын алыштыра торган документының сериясе, номеры һәм аның бирелү датасы, паспортны яисә граждан паспортын алыштыра торган документны биргән органның исеме яисә коды, төп эш яисә хезмәт урыны, биләгән вазыйфасы (төп эш яисә хезмәт урыны булмаган очракта – шөгыльләренең төре), яшәү урыны адресы, шулай ук аның вәкаләтләре күрсәтелә. Сайлау берләшмәсенең финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкиле өчен шулай ук аның түләү (исәп-хисап) документларын имзалау хокукы булуы да күрсәтелә.";

5) 39 статьяга түбәндәге эчтәлекле $3^1$ өлеш өстәргә:

"$3^1$. Инвалид булган һәм шуңа бәйле рәвештә тиешле сайлау округы буенча чыгарга ризалык бирү турындагы гаризаны мөстәкыйль язу, имза кәгазен таныклау, законда каралган башка документларны тутыру яисә таныклау мөмкинлеге булмаган зат үз кандидатурасын күрсәткән очракта, әлеге зат моның өчен башка зат ярдәменнән файдаланырга хокуклы. Мондый чакта әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 – 3 пунктларында күрсәтелгән документларны тутырганда яисә таныклаганда ярдәм күрсәтүче затның вәкаләтләре нотариаль таныкланган булырга тиеш.";

6) 40 статьяда:

а) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

"$1^1$) иҗтимагый берләшмәләрне теркәү өлкәсендәге функцияләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан бирелгән юридик затларның бердәй дәүләт реестрына сайлау берләшмәсе турында язма кертелү фактын раслый торган документның нотариаль таныкланган күчермәсен,

әгәр сайлау берләшмәсе юридик зат булмаса, шулай ук аны төзү турындагы карарны;";

б) түбәндәге эчтәлекле 3¹ өлеш өстәргә:

"3¹. Инвалид булган һәм шуңа бәйле рәвештә кандидатлар исемлеге составында чыгарга ризалык бирү турындагы гаризаны мөстәкыйль язу, имза кәгазен таныклау, законда каралган башка документларны тутыру яисә таныклау мөмкинлеге булмаган затны кандидат итеп күрсәткән очракта, әлеге зат моның өчен башка зат ярдәменнән файдаланырга хокуклы. Мондый чакта әлеге статьяның 3 өлешендәге 1 – 3 пунктларында күрсәтелгән документларны тутырганда яисә таныклаганда ярдәм күрсәтүче затның вәкаләтләре нотариаль таныкланган булырга тиеш.";

в) түбәндәге эчтәлекле 4¹ өлеш өстәргә:

"4¹. Кандидатлар исемлеге сайлауларны оештыручы сайлау комиссиясенә шул комиссия тарафыннан раслана торган рәвештә кәгазьдә язылган килеш бирелә. Кандидатлар исемлеге тегелгән, номерланган (бер биттә төзелгән исемлектән тыш), сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиленең имзасы, шулай ук сайлау берләшмәсенең мөһере белән (әгәр сайлау берләшмәсе юридик зат булса) таныкланган булырга тиеш.";

г) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5. Сайлауларны оештыручы сайлау комиссиясе документларны алган көннән соң өч көн эчендә сайлау берләшмәсе тарафыннан күрсәтелгән кандидатлар исемлеген таныклый. Әлеге статьяның 1 – 3 өлешләрендә күрсәтелгән документларның булмавы, кандидатлар исемлеген күрсәтүгә карата "Сәяси партияләр турында" Федераль законда, "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законда каралган таләпләрнең үтәлмәве кандидатлар исемлеген таныклаудан баш тарту өчен нигез була.";

7) 41 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 5 – 7 пунктлар өстәргә:

"5) иҗтимагый берләшмәләрне теркәү өлкәсендәге функцияләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан бирелгән юридик затларның бердәй дәүләт реестрына сайлау берләшмәсе турында язма кертелү фактын раслый торган документның сәяси партиянең, башка иҗтимагый берләшмәнең йә аларның региональ бүлекләренең яисә башка структур бүлекчәләренең даими эшләүче җитәкче органы тарафыннан рәсми таныкланган күчермәсен, әгәр сайлау берләшмәсе юридик зат булмаса, шулай ук аны төзү турында карарны;

6) сәяси партиянең, башка иҗтимагый берләшмәнең йә аларның региональ бүлекләренең яисә башка структур бүлекчәләренең даими эшләүче җитәкче органы тарафыннан рәсми таныкланган сәяси партия, башка иҗтимагый берләшмә уставы күчермәсен;

7) кандидат буларак күрсәтелә торган кандидатураны сәяси партиянең, башка иҗтимагый берләшмәнең тиешле органы белән килештерүне раслый торган

документны, әгәр мондый килештерү сәяси партия, башка иҗтимагый берләшмә уставында каралган булса.";

б) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ өлеш өстәргә:

"$4^1$. Инвалид булган һәм шуңа бәйле рәвештә тиешле сайлау округы буенча чыгарга ризалык бирү турындагы гаризаны мөстәкыйль язу, имза кәгазен таныклау, законда каралган башка документларны тутыру һәм таныклау мөмкинлеге булмаган затны кандидат итеп күрсәткән очракта, әлеге зат моның өчен башка зат ярдәменнән файдаланырга мөмкин. Мондый чакта әлеге статьяның 1 өлешендәге 1, 2 пунктларында һәм 2 өлешендә күрсәтелгән документларны тутырганда яисә таныклаганда ярдәм күрсәтүче затның вәкаләтләре нотариаль таныкланган булырга тиеш.";

8) 42 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

"3) иҗтимагый берләшмәләрне теркәү өлкәсендәге функцияләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан бирелгән юридик затларның бердәй дәүләт реестрына сайлау берләшмәсе турында язма кертелү фактын раслый торган документның нотариаль таныкланган күчермәсен, әгәр сайлау берләшмәсе юридик зат булмаса, шулай ук аны төзү турындагы карарны.";

б) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ өлеш өстәргә:

"$3^1$. Инвалид булган һәм шуңа бәйле рәвештә тиешле сайлау округы буенча чыгарга ризалык бирү турындагы гаризаны мөстәкыйль язу, имза кәгазен таныклау, законда каралган башка документларны тутыру яисә таныклау мөмкинлеге булмаган затны кандидат итеп күрсәткән очракта, әлеге зат моның өчен башка зат ярдәменнән файдаланырга хокуклы. Мондый чакта әлеге статьяның 2 өлешендәге 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән документларны тутырганда яисә таныклаганда ярдәм күрсәтүче затның вәкаләтләре нотариаль таныкланган булырга тиеш.";

9) 43 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"43 статья. **Кандидатларны, кандидатлар исемлекләрен күрсәтүне хуплау рәвешләре**

1. Кандидатны, кандидатлар исемлеген күрсәтү, әлеге статьяның 2, 4, 6 һәм 8 өлешләрендә каралган очраклардан тыш, сайлаучылар тарафыннан имза кәгазьләренә үз имзаларын кертү юлы белән хупланырга тиеш.

2. Кандидатларның федераль исемлеге моңа кадәр узган Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлауларның рәсми басылып чыккан нәтиҗәләре нигезендә депутат мандатларын бүлешүгә ("Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында" Федераль законның $82^1$ статьясы нигезендә кандидатларның депутат мандаты тапшырылган федераль исемлегенә) кертелгән сәяси партия тарафыннан күрсәтелгән кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү, шулай ук мондый сәяси партиянең региональ бүлекләре яисә башка структур бүлекчәләре (әгәр сәяси партия уставында бу каралган булса) тарафыннан күрсәтелгән кандидатларны, кандидатлар исемлекләрен теркәү, әгәр күрсәтелгән рәсми бастырып чыгару

кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү өчен кирәкле документлар сайлау комиссиясенә тапшырылганчы башкарылган булса, сайлаучылар имзаларын җыймыйча гына гамәлгә ашырыла. Шулай ук кандидатлар исемлекләре Россия Федерациясе субъектларының кимендә өчтән берендә дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарында сайлаулар билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (басылган) көнгә гамәлдә булган депутат мандатларын бүлешүгә ("Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законның 35 статьясындагы 17 пунктында каралган Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатлар исемлекләренә) кертелгән сәяси партия тарафыннан күрсәтелгән кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү һәм мондый сәяси партиянең региональ бүлекләре яисә башка структур бүлекчәләре (әгәр сәяси партия уставында бу каралган булса) тарафыннан күрсәтелгән кандидатларны, кандидатлар исемлекләрен теркәү дә сайлаучылар имзаларын җыймыйча гына гамәлгә ашырыла.

3. Әлеге статьяның 2 өлешенең гамәли көче кагыла торган сәяси партияләр исемлеге федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан төзелә, гомуми файдаланудагы "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үз сайтында урнаштырыла һәм дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнары депутатларын сайлаулар нәтиҗәләре буенча яңартыла.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советына сайлауларда, шулай ук җирле үзидарә органнарына сайлауларда кандидатлар исемлеге моңа кадәр узган Дәүләт Советы депутатларын сайлауларның рәсми басылып чыккан нәтиҗәләре нигезендә депутат мандатларын бүлешүгә (әлеге Кодексның $97^1$ статьясы нигезендә депутат мандаты тапшырылган кандидатлар исемлегенә) кертелгән сәяси партия тарафыннан күрсәтелгән кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү, шулай ук мондый сәяси партиянең региональ бүлекләре яисә башка структур бүлекчәләре (әгәр сәяси партия уставында бу каралган булса) тарафыннан күрсәтелгән кандидатларны, кандидатлар исемлекләрен теркәү, әгәр күрсәтелгән рәсми бастырып чыгару кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү өчен кирәкле документлар сайлау комиссиясенә тапшырылганчы башкарылган булса, сайлаучылар имзаларын җыймыйча гына гамәлгә ашырыла.

5. Әлеге статьяның 4 өлешенең гамәли көче кагыла торган сәяси партияләр исемлеге Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан төзелә, гомуми файдаланудагы "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үз сайтында урнаштырыла һәм Дәүләт Советы депутатларын сайлаулар нәтиҗәләре буенча яңартыла.

6. Муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнарына сайлауларда кандидатлар исемлеге шушы муниципаль берәмлекнең моңа кадәр узган вәкиллекле органы депутатларын сайлауларның рәсми басылып чыккан нәтиҗәләре нигезендә (җирлекнең җирле үзидарә органнарына сайлауларда – шулай ук тиешле муниципаль районның моңа кадәр узган вәкиллекле органы депутатларын сайлауларның рәсми басылып чыккан нәтиҗәләре нигезендә) депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән сәяси партия тарафыннан күрсәтелгән

кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү, шулай ук мондый сәяси партиянең региональ бүлекләре яисә башка структур бүлекчәләре (әгәр сәяси партия уставында бу каралган булса) тарафыннан күрсәтелгән кандидатларны, кандидатлар исемлекләрен теркәү, әгәр күрсәтелгән рәсми бастырып чыгару кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү өчен кирәкле документлар тиешле сайлау комиссиясенә тапшырылганчы башкарылган булса, сайлаучылар имзаларын җыймыйча гына гамәлгә ашырыла.

7. Әлеге статьяның 6 өлешенең гамәли көче кагыла торган сәяси партияләрнең исемлеге тиешле муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатларын сайлауларны оештыручы сайлау комиссиясе тарафыннан төзелә, гомуми файдаланудагы "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үз сайтында һәм (яисә) аның мөрәҗәгате буенча Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе сайтында урнаштырыла һәм бу муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатларын сайлаулар нәтиҗәләре буенча яңартыла.

8. Сайлау округында сайлаучылар вәкиллегенең уртача нормасы ун мең сайлаучыдан артыграк булмаган муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнарына сайлаулар уздырганда, кандидатларны теркәүнең белдерү тәртибе билгеләнә. Бу очракта кандидатларны күрсәтүне хуплап сайлаучылар имзаларын җыю башкарылмый.

9. Әгәр кандидатны, кандидатлар исемлеген күрсәтүне хуплап сайлаучылар имзалары җыелса, кандидатны, кандидатлар исемлеген хуплап, тиешле сайлау округы территориясендә теркәлгән сайлаучыларның гомуми саныннан 1 процент күләмендә имзалар җыелырга, әмма ул 10 имзадан да ким булмаска тиеш. Күпмандатлы сайлау округында һәр кандидатны теркәү өчен кирәкле имзалар саны тиешле сайлау округы территориясендә теркәлгән сайлаучыларның депутат мандатлары санына бүленгән саныннан 1 процент тәшкил итә, әмма ул 10 имзадан да ким булмаска тиеш.

10. Вакытыннан алда сайлаулар уздырылган очракта, кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү өчен кирәкле сайлаучылар имзаларының саны икеләтә киметелә, әмма ул 10 имзадан да кимрәк булмаска тиеш.";

10) 45 статьяның 4 өлешендә "43 статьясындагы 2 өлешендә яисә $2^1$ өлешендә" сүзләрен "43 статьясындагы 2 өлешендә, яисә 4 өлешендә, яисә 6 өлешендә" сүзләренә алмаштырырга;

11) 47 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Тиешле сайлау комиссиясе кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү өчен кирәкле документларны алган көннән ун көн эчендә кандидатны, кандидатлар исемлеген күрсәтү тәртибенең закон таләпләренә туры килүен тикшерергә һәм кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү турында карар йә мондый теркәүдән баш тарту турында дәлилләнгән карар кабул итәргә тиеш.";

12) 55 статьяның 3 өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Комиссияләр шулай ук инвалид булган сайлаучыларга мәгълүмат бирү буенча кирәкле чаралар күрәләр.";

13) 63 статьяда:

а) 3 өлешнең беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Теркәлгән кандидатның, кандидатлар исемлеген теркәгән сайлау берләшмәсенең мөрәҗәгате буенча җыелышлар рәвешендә гавами агитация чаралары үткәрү өчен яраклы һәм дәүләт яисә муниципаль милектәге бина теркәлгән кандидатка, аның ышанычлы затларына, сайлау берләшмәсе вәкилләренә сайлаучылар белән очрашулар уздыру өчен Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны уздырганда – территория комиссиясе тарафыннан, ә муниципаль сайлауларны уздырганда муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән вакытка бинаның милекчесе, хуҗасы тарафыннан бушлай бирелә.";

б) 4 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Теркәлгән кандидатка, сайлау берләшмәсенә бина бирелгән очракта, бинаның милекчесе, хуҗасы, бинаны биргән көннән соң икенче көннән дә соңга калмыйча, Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны уздырганда – территория комиссиясенә, ә муниципаль сайлауларны уздырганда муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә бина бирү факты, аның бирелү шартлары турында, шулай ук агитация чоры дәвамында бу бинаның башка теркәлгән кандидатларга, сайлау берләшмәләренә бирелергә мөмкин булуы турында язма рәвештә хәбәр итәргә тиешләр.";

в) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ өлеш өстәргә:

"$4^1$. Теркәлгән кандидатка, сайлау берләшмәсенә бина бирелү факты турында хәбәрнамә алган комиссия хәбәрнамәне алган вакыттан ике тәүлек эчендә андагы мәгълүматны гомуми файдаланудагы "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга яисә аны теркәлгән башка кандидатларга, сайлау берләшмәләренә бүтән ысул белән җиткерергә тиеш.";

14) 67 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округлары буенча кандидатлар күрсәткән сайлау берләшмәсе сайлау фондын төземи.";

б) 3 өлешнең беренче җөмләсендә ", шулай ук финанс документлары өчен мөһер үрнәге китерелә" сүзләрен төшереп калдырырга;

15) 73 статьяга түбәндәге эчтәлекле $5^1$ өлеш өстәргә:

"$5^1$. Күрү сәләте буенча инвалидлар булган сайлаучыларга мәгълүмат бирү өчен мәгълүмат тактасында әлеге статьяның 3 һәм 4 өлешләрендә күрсәтелгән, эре шрифт белән һәм (яисә) рельефлы-нокталы Брайль шрифты кулланып башкарылган материаллар урнаштырыла. Мәгълүмат такталарында шундый материаллар урнаштырыла торган сайлау участоклары сайлауларны оештыручы комиссия карары белән билгеләнә.";

16) 74 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"74 статья. **Бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы**

1. Үзен сайлаучылар исемлегенә керткән сайлау участогының тавыш бирү бинасына тавыш бирү көнендә килү мөмкинлеге булмаган сайлаучы территория

комиссиясендә (муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясендә, округ сайлау комиссиясендә) (тавыш бирү көненә кадәр 45 – 20 көн кала) йә участок комиссиясендә (тавыш бирү көненә кадәр 19 – 1 көн кала) бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын алырга һәм, сайлаучы тавыш бирү көнендә актив сайлау хокукына ия була торган сайлау округы чикләрендә кайсы сайлау участогында була торган булса, шул сайлау участогында тавыш бирүдә катнашырга хокуклы.

2. Федераль законда билгеләнгән очракларда Дәүләт Советы депутатларын сайлауларда һәм муниципаль сайлауларда бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын бирү срокларын билгеләгәндә федераль закон нормалары кулланыла.

3. Бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары катгый хисап документлары булалар, һәм сайлаулар уздырыла торган бөтен территориядә аларга бердәй номер бирелә. Кабат тавыш бирү күздә тотыла торган сайлауларда кулланыла торган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгының өзмә талоны булырга тиеш. Бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законга 2 яисә 3 нче кушымтадагы рәвеш буенча әзерләнә. Бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгының тексты, бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларының саны, бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрының рәвеше, тавыш бирү көненә кадәр 60 көннән дә соңга калмыйча, сайлауларны оештыручы комиссия тарафыннан раслана. Бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын әзерләгәндә аларны охшаш күчермәләрдән яклау ысуллары да шушы комиссия тарафыннан билгеләнә.

4. Бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын әзерләгәндә, аларны охшаш күчермәләрдән яклау максатларында, су тамгалары булган һәм (яисә) типография ысулы белән төшерелгән микрошрифтлы язу һәм (яисә) яклау челтәре булган кәгазь һәм (яисә) башка махсус яклау элементлары кулланыла.

5. Бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын әзерләүгә заказ урнаштыру сайлауларны оештыручы комиссия тарафыннан аның карары нигезендә үзәкләштерелгән рәвештә гамәлгә ашырыла.

6. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән сайлау комиссиясе сайлаучының бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы кирәк булуның сәбәбе күрсәтелгән язма гаризасы нигезендә бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын сайлаучының шәхсән үзенә йә нотариаль таныкланган ышанычнамә нигезендә аның вәкиленә тапшыра. Ышанычнамә шулай ук стационар дәвалау-профилактикалау учреждениесе администрациясе тарафыннан (әгәр сайлаучы шул учреждениедә дәвалана торган булса), җинаятьләр кылуда шик белдерелгән яисә гаепләнүче затлар сак астында тотыла торган учреждение администрациясе тарафыннан (әгәр сайлаучы шик белдерелгән яисә гаепләнүче зат буларак шул учреждениедә тотылса) таныкланырга мөмкин.

7. Бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын бирүче комиссия рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы аңа сайлаучының фамилиясен, исемен һәм атасының исемен, аның

паспортының яисә граждан паспортын алыштыра торган документының сериясен һәм номерын, сайлаучы сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлау участогының номерын, участок комиссиясенең адресын, муниципаль берәмлекнең һәм Россия Федерациясе субъектының исемнәрен, сайлау участогы төзелгән территориядәге бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округының номерын һәм (яисә) исемен (әгәр сайлаулар бермандатлы һәм (яисә) күпмандатлы сайлау округлары буенча уздырыла торган булса), бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын биргән комиссиянең исемен кертә. Әлеге Кодексның 128[1] статьясындагы 1 өлеше нигезендә сайлауларда кабат тавыш бирү үткәрелергә мөмкин булган очракта, сайлаучы, сайлау участогы һәм тиешле комиссия турында күрсәтелгән белешмәләр шулай ук бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгының өзмә талонына да кертеләләр. Бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын бирүче комиссиянең рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгында (шулай ук өзмә талонда) үзенең фамилиясен һәм инициалларын, бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын бирү датасын куя, имза сала һәм тиешле комиссиянең мөһерен куя.

8. Бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын алганда (сайлауларда кабат тавыш бирү үткәрелгән очракта – бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын өзмә талонсыз гына), сайлаучы бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрының яисә сайлаучылар исемлегенең тиешле графаларында үз паспортының яисә граждан паспортын алыштыра торган документының сериясен һәм номерын күрсәтә һәм имза сала. Бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрында сайлаучының яшәү урыны адресы күрсәтелергә тиеш. Бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы ышанычнамә нигезендә сайлаучының вәкиле тарафыннан алынган очракта, бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрының яисә сайлаучылар исемлегенең тиешле графаларында сайлаучының паспортының яисә граждан паспортын алыштыра торган документының сериясе һәм номеры күрсәтелә, шул ук вакытта сайлаучының вәкиле үзенең фамилиясен, исемен һәм атасының исемен, паспортының яисә граждан паспортын алыштыра торган документының сериясен һәм номерын күрсәтә һәм имза сала. Шуннан соң сайлаучының вәкиленнән ышанычнамә кире алына һәм тиешле рәвештә бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрына, сайлаучылар исемлегенә өстәп куела.

9. Сайлаучыга бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын биргән территория комиссиясе (муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе, округ сайлау комиссиясе) рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрының тиешле графаларында бирелгән бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгының номерын күрсәтә һәм имза сала. Территория комиссиясе (муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе, округ сайлау комиссиясе) тавыш бирү көненә кадәр 20 көн алдан участок комиссияләренә сайлаучылар исемлегенең беренче нөсхәсе белән бергә бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрыннан таныкланган өземтәләр җибәрә, аларда тиешле сайлау

участоклары территорияләрендә теркәлгән, бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын алган сайлаучылар турында белешмәләр күрсәтелә. Тиешле өземтә нигезендә участок комиссиясе әгъзасы сайлаучылар исемлегенең "Аерым тамгалар" графасында, бирелгән бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгының номерын күрсәтеп, "Территория комиссиясендә (муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясендә, округ сайлау комиссиясендә) ____ номерлы бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы алды" дигән тамга ясый һәм имза сала.

10. Участок комиссиясендә сайлаучыга бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы бирелгәндә, сайлаучыга бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын биргән участок комиссиясе рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы сайлаучылар исемлегенең "Аерым тамгалар" графасында, бирелгән бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгының номерын күрсәтеп, "_____ номерлы бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы алды" дигән тамга ясый һәм имза сала.

11. Үзенә бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы бирелгән сайлаучы (шул исәптән ышанычнамә нигезендә үз вәкиле аша) шушы сайлауларда тиешле сайлау участогында сайлаучылар исемлегеннән участок комиссиясе тарафыннан төшереп калдырыла һәм, тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе беркетмәсе төзелгәндә, теркәлгән сайлаучылар рәтендә исәпкә алынмый.

12. Бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын кабат бирү рөхсәт ителми. Бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын югалткан очракта аның дубликаты бирелми.

13. Файдаланылмаган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары тавыш бирү көнендә тавыш бирү вакыты башланганчы юкка чыгарыла. Кабат тавыш бирү үткәрелгән очракта, сайлау комиссиясе кабат тавыш бирү билгеләгән көннән алып кабат тавыш бирү көненнән алдагы көнгә кадәр чорда сайлаучыларга бирелгән бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларының файдаланылмаган өзмә талоннары юкка чыгарыла. Кабат тавыш бирү көнендә тавыш бирү вакыты башланганчы файдаланылмаган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары өзмә талоннары белән бергә юкка чыгарыла. Файдаланылмаган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын һәм өзмә талоннарны юкка чыгару турындагы белешмәләр федераль закон нигезендә, аларның санын, шулай ук бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларының номерларын күрсәтеп, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе раслаган рәвеш буенча төзелгән актка тиешле сайлау комиссиясе тарафыннан кертелә.

14. Сайлаучы, тавыш бирү көнендә бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын күрсәткәч, тавыш бирү көнендә булачак сайлау участогында өстәмә рәвештә сайлаучылар исемлегенә кертелә. Участок комиссиясе сайлаучылар исемлегенең "Аерым тамгалар" графасында, сайлаучы тарафыннан күрсәтелгән бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгының номерын күрсәтеп, "____ номерлы бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы буенча тавыш бирде" дигән тамга ясый. Шуннан соң, сайлауларда кабат тавыш бирү каралган очрактан тыш, бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы сайлаучыдан кире алына. Мондый очракта гомуми сайлаулар уздырылганда – сайлаучылардан өзмә талон, ә

кабат тавыш бирү үткәрелгәндә бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы кире алына. Сайлаучыларны сайлаучылар исемлегенә кертү өчен нигез булган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары (өзмә талоннар) шушы исемлек белән бергә саклана.

15. Бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгының бланкы югалган очракта, мондый югалу фактын билгеләгән комиссия кичекмәстән тиешле акт төзи һәм карар кабул итә, анда бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгының югалган бланкы номеры, бланкның югалу факты һәм югалу сәбәбе күрсәтелә. Бу карар шул ук көнне турыдан-туры югарырак комиссиягә һәм сайлауларны оештыручы комиссиягә җиткерелә. Сайлауларны оештыручы комиссия шушы карар нигезендә тиешле бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын гамәлгә яраксыз дип таный, шул хакта барлык түбәнгерәк комиссияләргә кичекмәстән хәбәр ителә. Гамәлгә яраксыз бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы сайлаучыны сайлаучылар исемлегенә кертү өчен нигез була алмый. Сайлаучы мондый бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын күрсәткәндә, бу таныклык кире алынырга тиеш.

16. Бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын тапшыру һәм бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын исәпкә алу тәртибе, шул исәптән "Сайлаулар" ДАСын кулланып, федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана.";

17) 75 статьяга түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

"$2^1$. Күрү сәләте буенча инвалид булган сайлаучыларга ярдәм итү өчен сайлауларны оештыручы сайлау комиссиясе карары белән бюллетеньне мөстәкыйль тутыру өчен махсус трафаретлар, шул исәптән рельефлы-ноктал Брайль шрифтын кулланып әзерләнә. Үзләре өчен шундый трафаретлар әзерләнә торган сайлау участоклары сайлауларны оештыручы комиссия карары белән билгеләнә.";

18) 76 статьяның 13 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"13. Бюллетень алганда мөстәкыйль рәвештә имза салу яисә бюллетеньне тутыру, электрон тавыш бирүдә катнашу мөмкинлеге булмаган сайлаучы моның өчен комиссия әгъзасы, теркәлгән кандидат, сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиле, кандидатның, сайлау берләшмәсенең ышанычлы заты, күзәтүче булмаган бүтән сайлаучы ярдәменнән файдаланырга хокуклы. Мондый очракта сайлаучы бюллетень тутыру, электрон тавыш бирүдә катнашу өчен ярдәмнән файдаланырга нияте барлыгы турында комиссиягә телдән хәбәр итә. Бу чакта сайлаучылар исемлегенең тиешле графасында (графаларында) сайлаучыга ярдәм итүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспортының яисә паспортын алыштыра торган документының сериясе һәм номеры күрсәтелә.";

19) 77 статьяга түбәндәге эчтәлекле $11^1$ өлеш өстәргә:

"$11^1$. Инвалид булуы яисә сәламәтлеге аркасында сайлаучының бюллетень алганда мөстәкыйль рәвештә имза салу яисә бюллетень тутыру мөмкинлеге булмаган очракта, ул моның өчен әлеге Кодексның 76 статьясындагы 13 өлешендә билгеләнгән тәртиптә башка сайлаучы ярдәменнән файдаланырга хокуклы.";

20) 78 статьяның 2 өлешендәге 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5) түбәндәге тәртиптә беркетмә юллары:

1 юл: тавыш бирү тәмамланган мизгелгә исемлеккә кертелгән сайлаучылар саны;

2 юл: участок комиссиясе тарафыннан алынган бюллетеньнәр саны;

3 юл: тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасында сайлаучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

4 юл: тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән сайлаучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

5 юл: юкка чыгарылган бюллетеньнәр саны;

6 юл: тавыш бирү өчен күчерелмә әрҗәләрдәге бюллетеньнәр саны;

7 юл: тавыш бирү өчен стационар әрҗәләрдәге бюллетеньнәр саны;

8 юл: гамәлгә яраксыз бюллетеньнәр саны;

9 юл: гамәлгә яраклы бюллетеньнәр саны;

10 юл: участок комиссиясе тарафыннан алынган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны;

11 юл: тавыш бирү көненә кадәр сайлау участогында сайлаучыларга участок комиссиясе тарафыннан бирелгән бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны;

12 юл: бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары буенча сайлау участогында тавыш биргән сайлаучылар саны;

13 юл: бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларының сайлау участогында юкка чыгарылган саны;

13-1 юл: территория комиссиясе (муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе, округ сайлау комиссиясе) тарафыннан сайлаучыларга бирелгән бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны;

13-2 юл: юкка чыккан бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны;

14 юл: юкка чыккан бюллетеньнәр саны;

15 юл: алганда исәпкә алынмаган бюллетеньнәр саны.";

21) 79 статьяда:

а) 5 өлештә:

1 пунктта "территория һәм (яисә) участок комиссияләрендә" сүзләрен "территория комиссиясендә (муниципаль берәмлек сайлау комиссиясендә, округ сайлау комиссиясендә) һәм участок комиссиясендә" сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"6) территория комиссиясе (муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе, округ сайлау комиссиясе) тарафыннан сайлаучыларга бирелгән бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны.";

б) 6 өлештә:

беренче абзацның соңгы җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Игълан ителгән күрсәткечләр тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның киңәйтелгән рәвешенең тиешле юлларына кертелә, тавышларны санауның

техник чаралары кулланылган очракта – беркетмәнең киңәйтелгән рәвешенең түбәндәге тиешле юлларына гына:";

түбәндәге эчтәлекле $6^1$ пункт өстәргә:

"$6^1$) 13 юлга – бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларының сайлау участогында юкка чыгарылган саны;";

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"7) 13-1 юлга – сайлаучыларга территория комиссиясе (муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе, округ сайлау комиссиясе) тарафыннан бирелгән бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны.";

түбәндәге эчтәлекле унынчы абзац өстәргә:

"Әлеге гамәлләрне башкарганнан соң түбәндәге контроль чагыштырманы тикшерү уздырыла: участок комиссиясе тарафыннан алынган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны тавыш бирү көненә кадәр сайлау участогында сайлаучыларга участок комиссиясе тарафыннан бирелгән бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны һәм сайлау участогында юкка чыгарылган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны суммасына тигез булырга тиеш. Әгәр әлеге контроль чагыштырма үтәлмәсә, участок комиссиясе сайлаучылар исемлегенә кертелгән күрсәткечләрне һәм юкка чыгарылган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын өстәмә санау турында карар кабул итә. Әгәр өстәмә санау нәтиҗәсендә әлеге контроль чагыштырма тагын да үтәлмәсә, участок комиссиясе тиешле карар кабул итә, карар тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә кушып бирелә, һәм участок комиссиясе аерма турындагы күрсәткечләрне тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның киңәйтелгән рәвешенең 13-2 юлына кертә. Әгәр әлеге контроль чагыштырма үтәлсә, 13-2 юлда "0" саны куела.";

22) 80 статьяның 7 өлешенә түбәндәге эчтәлекле яңа икенче җөмлә өстәргә: "Тавыш бирү йомгаклары турындагы (сайлаулар нәтиҗәләре турындагы) беркетмәгә шулай ук тиешле комиссия тарафыннан алынган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны, түбәнгерәк комиссияләргә бирелгән бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны, тиешле комиссия тарафыннан юкка чыгарылган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларының файдаланылмаган саны һәм бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларының югалган саны турында күрсәткечләр кертелә.";

23) 111 статьяның 3 өлешендәге беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Депутатлар саны 20 һәм аннан да күбрәк булган муниципаль районның, шәһәр округының, шулай ук сайлаучылары саны 100 меңнән артыграк булган бүтән муниципаль берәмлек муниципаль сайлауларда сайлана торган вәкиллекле органындагы депутат мандатларының кимендә яртысы сайлау берләшмәләре күрсәткән кандидатлар исемлекләре арасында кандидатлар исемлекләренең һәрберсе тарафыннан алынган сайлаучылар тавышлары санына пропорциональ рәвештә бүленә.";

24) 117 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Җирле үзидарәнең вәкиллекле органында депутат мандатларын бүлешүгә һәрберсе сайлаучылар тавышларының 5 процентын һәм аннан да күбрәген алган кандидатларның теркәлгән исемлекләре кертелә, бу чакта мондый исемлекләр кимендә ике булырга һәм шушы исемлекләр өчен бердәм сайлау округы буенча тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның барлыгы 50 проценттан артыграгы тавыш биргән булырга тиеш. Бу очракта кандидатларның бүтән исемлекләре бердәм сайлау округы буенча депутат мандатларын бүлешүгә кертелми.".

**2 статья**

"Татарстан Республикасы референдумы турында" 2003 елның 9 августындагы 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 8; 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 10 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 31 статьяның 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Комиссияләр инвалидлар булган референдумда катнашучыларга мәгълүмат җиткерү буенча да кирәкле чаралар күрә.".

2) 47 статьяга түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

"$4^1$. Күрү сәләте буенча инвалидлар булган референдумда катнашучыларга мәгълүмат бирү өчен мәгълүмат стендында әлеге статьяның 3 пунктында күрсәтелгән, эре шрифт белән һәм (яисә) рельефлы-нокталы Брайль шрифты кулланып башкарылган материаллар урнаштырыла. Мәгълүмат стендларында мондый материаллар урнаштырылган референдум участоклары референдум оештыручы комиссия карары белән билгеләнә.";

3) 48 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"48 статья. **Референдумда тавыш бирү өчен бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы**

1. Үзен референдумда катнашучылар исемлегенә керткән референдум участогының тавыш бирү бинасына тавыш бирү көнендә килү мөмкинлеге булмаган референдумда катнашучы территория комиссиясендә (тавыш бирү көненә кадәр 45 – 20 көн кала) йә участок комиссиясендә (тавыш бирү көненә кадәр 19 – 1 көн кала) бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын алырга һәм, референдумда катнашучы референдумда катнашу хокукына ия булган Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә тавыш бирү көнендә кайсы референдум участогында булса, шул референдум участогында тавыш бирүдә катнашырга хокуклы.

2. Федераль законда билгеләнгән очракларда бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү срокларын билгеләгәндә референдумда федераль закон нормалары кулланыла.

3. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары катгый хисаплылык документлары була һәм референдум уздыруның бөтен территориясендә бердәй нумерациягә ия була. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу

хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законның 2 нче кушымтасы нигезендәге рәвеш буенча әзерләнә. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының тексты, бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларының саны, бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрының рәвеше, тавыш бирү көненә кадәр 60 көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын әзерләгәндә шулай ук аларны охшатып ясаудан яклау алымнары да Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

4. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын охшатып ясаудан яклау максатларында, аларны әзерләгәндә су билгеләре булган һәм (яисә) типография ысулы белән төшерелгән микрошрифтлы язу һәм (яисә) яклау челтәре булган кәгазь һәм (яисә) бүтән махсус яклау элементлары кулланыла.

5. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын әзерләүгә заказ урнаштыру Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан аның карары нигезендә үзәкләштерелгән рәвештә гамәлгә ашырыла.

6. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән референдум комиссияләре референдумда катнашучының бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы таләп ителү сәбәбен күрсәткән язма гаризасы нигезендә бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын референдумда катнашучының шәхсән үзенә йә нотариаль таныкланган ышанычнамә нигезендә аның вәкиленә тапшыра. Ышанычнамә шулай ук стационар дәвалау-профилактикалау учреждениесе администрациясе тарафыннан (әгәр референдумда катнашучы шул учреждениедә дәвалана торган булса), җинаятьләр кылуда шик белдерелгән яисә гаепләнүче затлар сак астында тотыла торган учреждение администрациясе тарафыннан да (әгәр референдумда катнашучы шик белдерелгән яисә гаепләнүче зат буларак шул учреждениедә тотылса) таныкланырга мөмкин.

7. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын бирүче комиссия рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы аңа референдумда катнашучының фамилиясен, исемен һәм атасының исемен, аның паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясен һәм номерын, референдумда катнашучы референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдум участогының номерын, участок комиссиясенең адресын, территорияләрендә референдум участогы төзелгән муниципаль берәмлекнең һәм Россия Федерациясе субъектының исемнәрен, бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын биргән комиссия исемен кертә. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын бирүче комиссия рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгында үзенең фамилиясен һәм инициалларын, бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы бирелгән датаны күрсәтә, имза сала һәм тиешле комиссиянең мөһерен суга.

8. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын алганда, референдумда катнашучы бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрының яисә референдумда катнашучылар исемлегенең тиешле графаларында үз паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясен һәм номерын күрсәтә һәм имза сала. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү

реестрында референдумда катнашучының яшәү урынының адресы күрсәтелергә тиеш. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын референдумда катнашучының вәкиле ышанычнамә нигезендә алган очракта, бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрының яисә референдумда катнашучылар исемлегенең тиешле графаларында референдумда катнашучы паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясе һәм номеры күрсәтелә, бу чакта референдумда катнашучының вәкиле үзенең фамилиясен, исемен һәм атасының исемен, паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясен һәм номерын күрсәтә һәм имза сала. Шуннан соң референдумда катнашучының вәкиленнән ышанычнамә алына һәм тиешенчә бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрына, референдумда катнашучылар исемлегенә кушып куела.

9. Референдумда катнашучыга бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын биргән территория комиссиясе рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының номерын бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрының тиешле графаларында күрсәтә һәм имза сала. Территория комиссиясе тавыш бирү көненә кадәр 20 көн кала участок комиссияләренә референдумда катнашучылар исемлегенең беренче нөсхәсе белән бергә бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрыннан таныкланган өземтәләрне җибәрә, аларда тиешле референдум участоклары территорияләрендә теркәлгән, бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары алган референдумда катнашучылар турында белешмәләр күрсәтелә. Тиешле өземтә нигезендә участок комиссиясе әгъзасы референдумда катнашучылар исемлегенең "Аерым тамгалар" графасында, бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының номерын күрсәтеп, "Территория комиссиясендә _____ номерлы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы алды" дигән тамга ясый һәм имза сала.

10. Референдумда катнашучыга бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы участок комиссиясендә бирелгәндә, референдумда катнашучыга бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын биргән участок комиссиясе рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы референдумда катнашучылар исемлегенең "Аерым тамгалар" графасында, бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының номерын күрсәтеп, "_____ номерлы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы алды" дигән тамга ясый һәм имза сала.

11. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы бирелгән референдумда катнашучы (шул исәптән ышанычнамә нигезендә аның вәкиле аша) әлеге референдумда тиешле референдум участогында референдумда катнашучылар исемлегеннән төшереп калдырыла һәм, тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе беркетмәсе төзелгәндә, теркәлгән референдумда катнашучылар санында исәпкә алынмый.

12. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын кабат бирү рөхсәт ителми. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы югалган очракта, аның дубликаты бирелми.

13. Файдаланылмаган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары тавыш бирү көнендә тавыш бирү вакыты башланганчы юкка чыгарыла. Файдаланылмаган бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын юкка чыгару турындагы белешмәләр

федераль закон нигезендә, аларның санын, шулай ук бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларының номерларын күрсәтеп, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе раслаган рәвеш буенча төзелгән актка тиешле комиссия тарафыннан кертелә.

14. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын тавыш бирү көнендә күрсәткәч, референдумда катнашучы тавыш бирү көнендә кайсы референдум участогында булса, шул референдум участогында референдумда катнашучылар исемлегенә өстәмә рәвештә кертелә. Участок комиссиясе референдумда катнашучылар исемлегенең "Аерым тамгалар" графасында, референдумда катнашучы күрсәткән бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының номерын күрсәтеп, "____ номерлы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы буенча тавыш бирде" дигән тамга ясый. Шуннан соң бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы референдумда катнашучыдан алына. Референдумда катнашучыларны референдумда катнашучылар исемлегенә кертү өчен нигез булган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары әлеге исемлек белән бергә саклана.

15. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының бланкы югалган очракта, мондый югалу фактын ачыклаган комиссия кичекмәстән тиешле акт төзи һәм карар кабул итә, карарда бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының югалган бланкы номеры, бланкның югалу факты һәм югалу сәбәбе күрсәтелә. Бу карар шул ук көнне территория комиссиясенә һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә җиткерелә. Шушы карар нигезендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тиешле бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын гамәлгә яраксыз дип таный, шул хакта барлык түбәнгерәк комиссияләргә кичекмәстән хәбәр ителә. Гамәлгә яраксыз бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы референдумда катнашучыны референдумда катнашучылар исемлегенә кертү өчен нигез булмый. Референдумда катнашучы мондый бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын күрсәткәндә, бу таныклык алынырга тиеш.

16. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын тапшыру һәм бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын исәпкә алу тәртибе, шул исәптән "Сайлаулар" ДАСын кулланып, федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана.";

4) 49 статьяга түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

"$2^1$. Күрү сәләте буенча инвалидлар булган референдумда катнашучыларга ярдәмгә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары буенча бюллетеньне мөстәкыйль тутыру өчен, шул исәптән рельефлы-ноктали Брайль шрифтын кулланып, махсус трафаретлар әзерләнә. Үзләре өчен мондый трафаретлар әзерләнә торган референдум участоклары референдум оештыручы комиссия карары белән билгеләнә.";

5) 50 статьяның 10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"10. Бюллетень алган өчен мөстәкыйль имза салу яисә бюллетень тутыру, электрон тавыш бирүдә катнашу мөмкинлеге булмаган референдумда катнашучы моның өчен комиссия әгъзасы, теркәлгән кандидат, референдум үткәрү буенча инициатив төркем әгъзасы яисә вәкаләтле вәкиле, күзәтүче булмаган башка

референдумда катнашучы ярдәменнән файдаланырга хокуклы. Мондый очракта референдумда катнашучы бюллетень тутыру, электрон тавыш бирүдә катнашу өчен ярдәмнән файдалану нияте турында комиссиягә телдән хәбәр итә. Бу чакта референдумда катнашучылар исемлегенең тиешле графасында (графаларында) референдумда катнашучыга ярдәм итүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм паспортының яисә паспортын алмаштыручы документының сериясе һәм номеры күрсәтелә.";

6) 51 статьяга түбәндәге эчтәлекле $11^1$ пункт өстәргә:

"$11^1$. Референдумда катнашучының инвалидлыгы аркасында яисә сәламәтлеге торышы буенча бюллетень алган өчен мөстәкыйль имза салу яисә бюллетень тутыру мөмкинлеге булмаган очракта, ул әлеге Законның 50 статьясындагы 10 пункты белән билгеләнгән тәртиптә башка референдумда катнашучы ярдәменнән файдаланырга хокуклы.";

7) 52 статьяның 2 пунктындагы "д" пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"д) түбәндәге тәртиптә беркетмә юллары:

1 юл: тавыш бирү тәмамланган мизгелгә исемлеккә кертелгән референдумда катнашучылар саны;

2 юл: участок комиссиясе тарафыннан алынган бюллетеньнәр саны;

3 юл: тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасында референдумда катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

4 юл: тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән референдумда катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

5 юл: юкка чыгарылган бюллетеньнәр саны;

6 юл: тавыш бирүнең күчерелмә әрҗәләрендәге бюллетеньнәр саны;

7 юл: тавыш бирүнең стационар әрҗәләрендәге бюллетеньнәр саны;

8 юл: гамәлгә яраксыз бюллетеньнәр саны;

9 юл: гамәлгә яраклы бюллетеньнәр саны;

9а юл: участок комиссиясе тарафыннан алынган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

9б юл: тавыш бирү көненә кадәр референдум участогында референдумда катнашучыларга участок комиссиясе тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

9в юл: бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча референдум участогында тавыш биргән референдумда катнашучылар саны;

9г юл: бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларының референдум участогында юкка чыгарылган саны;

9г-1 юл: территория комиссиясе тарафыннан референдумда катнашучыларга бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

9г-2 юл: бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларының югалган саны;

9д юл: югалган бюллетеньнәр саны;

9е юл: алганда исәпкә алынмаган бюллетеньнәр саны;

10 юл һәм аннан соңгы юллар: бюллетеньнәрдәге "Әйе" һәм "Юк" ("Хуплыйм" һәм "Каршы") позицияләре буенча референдумда катнашучылар тавышлары саны;";

8) 53 статьяда:

а) 5 пунктта:

"а" пунктчасында "территория һәм участок комиссияләрендә" сүзләрен "территория һәм (яисә) участок комиссияләрендә" сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле "е" пунктчасы өстәргә:

"е) референдумда катнашучыларга территория комиссиясе тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны.";

б) 6 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле "з" пунктчасы өстәргә:

"з) 9г-1 юлга – референдумда катнашучыларга территория комиссиясе тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны.";

түбәндәге эчтәлекле унынчы абзац өстәргә:

"Әлеге гамәлләрне башкарганнан соң түбәндәге контроль чагыштырманы тикшерү уздырыла: участок комиссиясе тарафыннан алынган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны тавыш бирү көненә кадәр референдум участогында референдумда катнашучыларга участок комиссиясе тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны һәм референдум участогында юкка чыгарылган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны суммасына тигез булырга тиеш. Әгәр әлеге контроль чагыштырма үтәлмәсә, участок комиссиясе референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән күрсәткечләрне һәм юкка чыгарылган бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын өстәмә санау турында карар кабул итә. Әгәр өстәмә санау нәтиҗәсендә әлеге контроль чагыштырма тагын да үтәлмәсә, участок комиссиясе тиешле карар кабул итә, карар тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә кушып бирелә, һәм участок комиссиясе аерма турындагы күрсәткечләрне тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның киңәйтелгән рәвешенең 9г-2 юлына кертә. Әгәр әлеге контроль чагыштырма үтәлсә, 9г-2 юлында "0" саны куела.";

в) 22 пунктның "в" пунктчасында "беркетмәнең киңәйтелгән рәвешенең 9г" сүзләрен "беркетмәнең киңәйтелгән рәвешенең 9г, 9г-1, 9г-2" сүзләренә алмаштырырга;

9) 54 статьяның 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле яңа бишенче җөмлә өстәргә: "Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә шулай ук тиешле комиссия тарафыннан алынган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны, түбәнгерәк комиссияләргә бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны, тиешле комиссия тарафыннан юкка чыгарылган бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларының файдаланылмаган саны һәм бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларының югалган саны турындагы күрсәткечләр дә кертелә.";

10) 55 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле бишенче абзац өстәргә:

"Референдум нәтиҗәләре турындагы беркетмәгә шулай ук тиешле комиссия тарафыннан алынган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны, түбәнгерәк комиссияләргә бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны, тиешле комиссия тарафыннан юкка чыгарылган бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларының файдаланылмаган саны һәм бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларының югалган саны турындагы күрсәткечләр дә кертелә.".

**3 статья**

"Җирле референдум турында" 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (II өлеш); 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 5 (II өлеш); 2010, № 10 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 33 статьяның 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Комиссияләр инвалидлар булган референдумда катнашучыларга мәгълүмат җиткерү буенча да кирәкле чаралар күрә.";

2) 49 статьяга түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

"$4^1$. Күрү сәләте буенча инвалидлар булган референдумда катнашучыларга мәгълүмат бирү өчен мәгълүмат стендында әлеге статьяның 3 пунктында күрсәтелгән, эре шрифт белән һәм (яисә) рельефлы-ноктала Брайль шрифты кулланып башкарылган материаллар урнаштырыла. Мәгълүмат стендларында мондый материаллар урнаштырылган референдум участоклары референдум оештыручы комиссия карары белән билгеләнә.";

3) 50 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"50 статья. **Референдумда тавыш бирү өчен бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы**

1. Үзен референдумда катнашучылар исемлегенә керткән референдум участогының тавыш бирү бинасына тавыш бирү көнендә килү мөмкинлеге булмаган референдумда катнашучы муниципаль берәмлек сайлау комиссиясендә (тавыш бирү көненә кадәр 45 – 20 көн кала) йә участок комиссиясендә (тавыш бирү көненә кадәр 19 – 1 көн кала) бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын алырга һәм, референдумда катнашучы референдумда катнашу хокукына ия булган муниципаль берәмлек территориясе чикләрендә тавыш бирү көнендә кайсы референдум участогында булса, шул референдум участогында тавыш бирүдә катнашырга хокуклы.

2. Федераль законда билгеләнгән очракларда референдумда бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү срокларын билгеләгәндә федераль закон нормалары кулланыла.

3. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары катгый хисаплылык документлары була һәм референдум уздыруның бөтен территориясендә бердәй нумерациягә ия була. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп

гарантияләре турында" Федераль законның 2 нче кушымтасы нигезендәге рәвеш буенча әзерләнә. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы тексты, бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны, бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрының рәвеше, тавыш бирү көненә кадәр 60 көннән дә соңга калмыйча, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе тарафыннан раслана. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын әзерләгәндә шулай ук аларны охшатып ясаудан яклау алымнары да муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

4. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын охшатып ясаудан яклау максатларында, аларны әзерләгәндә су билгеләре булган һәм (яисә) типография ысулы белән төшерелгән микрошрифтлы язу һәм (яисә) яклау челтәре булган кәгазь һәм (яисә) бүтән махсус яклау элементлары кулланыла.

5. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын әзерләүгә заказ урнаштыру муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе тарафыннан аның карары нигезендә үзәкләштерелгән рәвештә гамәлгә ашырыла.

6. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән референдум комиссияләре референдумда катнашучының бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы таләп ителү сәбәбен күрсәткән язма гаризасы нигезендә бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын референдумда катнашучының шәхсән үзенә йә нотариаль таныкланган ышанычнамә нигезендә аның вәкиленә тапшыра. Ышанычнамә шулай ук стационар дәвалау-профилактикалау учреждениесе администрациясе тарафыннан (әгәр референдумда катнашучы шул учреждениедә дәвалана торган булса), җинаятьләр кылуда шик белдерелгән яисә гаепләнүче затлар сак астында тотыла торган учреждение администрациясе тарафыннан да (әгәр референдумда катнашучы шик белдерелгән яисә гаепләнүче зат буларак шул учреждениедә тотылса) таныкланырга мөмкин.

7. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын бирүче комиссия рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы аңа референдумда катнашучының фамилиясен, исемен һәм атасының исемен, аның паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясен һәм номерын, референдумда катнашучы референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдум участогының номерын, участок комиссиясенең адресын, территорияләрендә референдум участогы төзелгән муниципаль берәмлекнең һәм Россия Федерациясе субъектының исемнәрен, бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын биргән комиссия исемен кертә. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын бирүче комиссия рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгында үзенең фамилиясен һәм инициалларын, бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы бирелгән датаны күрсәтә, имза сала һәм тиешле комиссиянең мөһерен суга.

8. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын алганда, референдумда катнашучы бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрының яисә референдумда катнашучылар исемлегенең тиешле графаларында үз паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясен һәм номерын күрсәтә һәм имза сала. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрында референдумда катнашучының яшәү урынының адресы күрсәтелергә

тиеш. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын референдумда катнашучының вәкиле ышанычнамә нигезендә алган очракта, бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрының яисә референдумда катнашучылар исемлегенең тиешле графаларында референдумда катнашучы паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясе һәм номеры күрсәтелә, бу чакта референдумда катнашучының вәкиле үзенең фамилиясен, исемен һәм атасының исемен, паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясен һәм номерын күрсәтә һәм имза сала. Шуннан соң референдумда катнашучының вәкиленнән ышанычнамә алына һәм тиешенчә бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрына, референдумда катнашучылар исемлегенә кушып куела.

9. Референдумда катнашучыга бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын биргән муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының номерын бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрының тиешле графаларында күрсәтә һәм имза сала. Муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе тавыш бирү көненә кадәр 20 көн кала участок комиссияләренә референдумда катнашучылар исемлегенең беренче нөсхәсе белән бергә бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрыннан таныкланган өземтәләрне җибәрә, аларда тиешле референдум участоклары территорияләрендә теркәлгән, бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары алган референдумда катнашучылар турында белешмәләр күрсәтелә. Тиешле өземтә нигезендә участок комиссиясе әгъзасы референдумда катнашучылар исемлегенең "Аерым тамгалар" графасында, бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының номерын күрсәтеп, "Муниципаль берәмлек сайлау комиссиясендә _____ номерлы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы алды" дигән тамга ясый һәм имза сала.

10. Референдумда катнашучыга бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы участок комиссиясендә бирелгәндә, референдумда катнашучыга бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын биргән участок комиссиясе рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы референдумда катнашучылар исемлегенең "Аерым тамгалар" графасында, бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының номерын күрсәтеп, "_____ номерлы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы алды" дигән тамга ясый һәм имза сала.

11. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы бирелгән референдумда катнашучы (шул исәптән ышанычнамә нигезендә аның вәкиле аша) әлеге референдумда тиешле референдум участогында референдумда катнашучылар исемлегеннән төшереп калдырыла һәм, тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе беркетмәсе төзелгәндә, теркәлгән референдумда катнашучылар санында исәпкә алынмый.

12. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын кабат бирү рөхсәт ителми. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы югалган очракта, аның дубликаты бирелми.

13. Файдаланылмаган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары тавыш бирү көнендә тавыш бирү вакыты башланганчы юкка чыгарыла. Файдаланылмаган бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын юкка чыгару турындагы белешмәләр

федераль закон нигезендә, аларның санын, шулай ук бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларының номерларын күрсәтеп, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе раслаган рәвеш буенча төзелгән актка тиешле комиссия тарафыннан кертелә.

14. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын тавыш бирү көнендә күрсәткәч, референдумда катнашучы тавыш бирү көнендә кайсы референдум участогында булса, шул референдум участогында референдумда катнашучылар исемлегенә өстәмә рәвештә кертелә. Участок комиссиясе референдумда катнашучылар исемлегенең "Аерым тамгалар" графасында, референдумда катнашучы күрсәткән бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының номерын күрсәтеп, "_____ номерлы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы буенча тавыш бирде" дигән тамга ясый. Шуннан соң бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы референдумда катнашучыдан алына. Референдумда катнашучыларны референдумда катнашучылар исемлегенә кертү өчен нигез булган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары әлеге исемлек белән бергә саклана.

15. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының бланкы югалган очракта, мондый югалу фактын ачыклаган комиссия кичекмәстән тиешле акт төзи һәм карар кабул итә, карарда бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының югалган бланкы номеры, бланкның югалу факты һәм югалу сәбәбе күрсәтелә. Бу карар шул ук көнне муниципаль берәмлек сайлау комиссиясенә җиткерелә. Шушы карар нигезендә муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе тиешле бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын гамәлгә яраксыз дип таный, шул хакта барлык түбәнгерәк комиссияләргә кичекмәстән хәбәр ителә. Гамәлгә яраксыз бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы референдумда катнашучыны референдумда катнашучылар исемлегенә кертү өчен нигез булмый. Референдумда катнашучы мондый бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын күрсәткәндә, бу таныклык алынырга тиеш.

16. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын тапшыру һәм бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын исәпкә алу тәртибе, шул исәптән "Сайлаулар" ДАСын кулланып, федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана.";

4) 51статьяга түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

"$2^1$. Күрү сәләте буенча инвалидлар булган референдумда катнашучыларга ярдәмгә муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе карары буенча бюллетеньне мөстәкыйль тутыру өчен, шул исәптән рельефлы-нокталы Брайль шрифтын кулланып, махсус трафаретлар әзерләнә. Үзләре өчен мондый трафаретлар әзерләнә торган референдум участоклары референдум оештыручы комиссия карары белән билгеләнә.";

5) 52 статьяның 10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"10. Бюллетень алган өчен мөстәкыйль имза салу яисә бюллетень тутыру, электрон тавыш бирүдә катнашу мөмкинлеге булмаган референдумда катнашучы моның өчен комиссия әгъзасы, референдум үткәрү буенча инициатив төркем әгъзасы яисә вәкаләтле вәкиле, күзәтүче булмаган башка референдумда катнашучы ярдәменнән файдаланырга хокуклы. Мондый очракта референдумда катнашучы

бюллетень тутыру, электрон тавыш бирүдә катнашу өчен ярдәмнән файдалану нияте турында комиссиягә телдән хәбәр итә. Бу чакта референдумда катнашучылар исемлегенең тиешле графасында (графаларында) референдумда катнашучыга ярдәм итүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм паспортының яисә паспортын алмаштыручы документының сериясе һәм номеры күрсәтелә.";

6) 53 статьяга түбәндәге эчтәлекле $11^1$ пункт өстәргә:

"$11^1$. Референдумда катнашучының инвалидлыгы аркасында яисә сәламәтлеге торышы буенча бюллетень алган өчен мөстәкыйль имза салу яисә бюллетень тутыру мөмкинлеге булмаган очракта, ул әлеге Законның 52 статьясындагы 10 пункты белән билгеләнгән тәртиптә башка референдумда катнашучы ярдәменнән файдаланырга хокуклы.";

7) 54 статьяның 2 пунктындагы "д" пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"д) түбәндәге тәртиптә беркетмә юллары:

1 юл: тавыш бирү тәмамланган мизгелгә исемлеккә кертелгән референдумда катнашучылар саны;

2 юл: участок комиссиясе тарафыннан алынган бюллетеньнәр саны;

3 юл: тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасында референдумда катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

4 юл: тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән референдумда катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

5 юл: юкка чыгарылган бюллетеньнәр саны;

6 юл: тавыш бирүнең күчерелмә әрҗәләрендәге бюллетеньнәр саны;

7 юл: тавыш бирүнең стационар әрҗәләрендәге бюллетеньнәр саны;

8 юл: гамәлгә яраксыз бюллетеньнәр саны;

9 юл: гамәлгә яраклы бюллетеньнәр саны;

9а юл: участок комиссиясе тарафыннан алынган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

9б юл: тавыш бирү көненә кадәр референдум участогында референдумда катнашучыларга участок комиссиясе тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

9в юл: бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча референдум участогында тавыш биргән референдумда катнашучылар саны;

9г юл: бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларының референдум участогында юкка чыгарылган саны;

9г-1 юл: муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе тарафыннан референдумда катнашучыларга бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

9г-2 юл: бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларының югалган саны;

9д юл: югалган бюллетеньнәр саны;

9е юл: алганда исәпкә алынмаган бюллетеньнәр саны;

10 юл һәм аннан соңгы юллар: бюллетеньнәрдәге "Әйе" һәм "Юк" ("Хуплыйм" һәм "Каршы") позицияләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары саны;";

8) 55 статьяда:

а) 5 пунктта:

"а" пунктчасында "участок комиссиясендә" сүзләрен "муниципаль берәмлек сайлау комиссиясендә һәм (яисә) участок комиссиясендә" сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле "е" пунктчасы өстәргә:

"е) референдумда катнашучыларга муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны.";

б) 6 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле "з" пунктчасы өстәргә:

"з) 9г-1 юлга – референдумда катнашучыларга муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны.";

түбәндәге эчтәлекле унынчы абзац өстәргә:

"Әлеге гамәлләрне башкарганнан соң түбәндәге контроль чагыштырманы тикшерү уздырыла: участок комиссиясе тарафыннан алынган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны тавыш бирү көненә кадәр референдум участогында референдумда катнашучыларга участок комиссиясе тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны һәм референдум участогында юкка чыгарылган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны суммасына тигез булырга тиеш. Әгәр әлеге контроль чагыштырма үтәлмәсә, участок комиссиясе референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән күрсәткечләрне һәм юкка чыгарылган бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын өстәмә санау турында карар кабул итә. Әгәр өстәмә санау нәтиҗәсендә әлеге контроль чагыштырма тагын да үтәлмәсә, участок комиссиясе тиешле карар кабул итә, карар тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә кушып бирелә, һәм участок комиссиясе аерма турындагы күрсәткечләрне тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның киңәйтелгән рәвешенең 9г-2 юлына кертә. Әгәр әлеге контроль чагыштырма үтәлсә, 9г-2 юлында "0" саны куела.";

в) 22 пунктның "в" пунктчасында "беркетмәнең киңәйтелгән рәвешенең 9г" сүзләрен "беркетмәнең киңәйтелгән рәвешенең 9г, 9г-1, 9г-2" сүзләренә алмаштырырга;

9) 56 статьяның 6 пунктына түбәндәге эчтәлекле бишенче абзац өстәргә:

"Референдум нәтиҗәләре турындагы беркетмәгә шулай ук тиешле комиссия тарафыннан алынган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны, түбәнгерәк комиссияләргә бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны, тиешле комиссия тарафыннан юкка чыгарылган бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларының файдаланылмаган саны һәм бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларының югалган саны турындагы күрсәткечләр дә кертелә.".

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 1 августы
№ 52-ТРЗ